КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 апрель г.Казань № 246

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1217 нче карары белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1217 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 февраль, 107 нче, 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче, 2024 ел, 30 май, 382 нче, 2024 ел, 12 сентябрь, 769 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Ятим балалар оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләренең, эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Ятим балалар оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче ярдәмчесе | 23 600 |
| Икенче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 23 720 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме<br>. | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 24 900 |
| | Хезмәт буенча инструктор | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Оештыручы педагог | 25 000 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Социаль педагог | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 25 140 |
| | Педагог-психолог | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Укытучы-дефектолог | 25 250 |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту һәм консультация бирү пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм гомуми белем программаларын һәм балаларга өстәмә белем бирә | 25 300 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | торган мәгариф программалары тормышка ашырылган башка структур бүлекчәләр мөдире (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан башка) | |

2.2. Ятим балалар оешмаларында мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 25 450 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханә бүлеге (секторы) мөдире | 26 650 |

2.3. Ятим балалар оешмаларында медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина абыйсы) | 25 240 |
| | Палата шәфкать туташы (посттагы) (палата медицина браты (посттагы) | |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы (физиотерапия буенча медицина браты) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 29 170 |

2.4. Ятим балалар оешмаларында эшчеләр гомумтармак һөнәрләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база окладлы күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 550 |

2.5. Ятим балалар оешмаларында хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга төп оклад күләме, сумтөп |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 240 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 24 430 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24 620 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24 820 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 25 050 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 25 250 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 25 450 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 400 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 600 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 800 |

2.6. Хезмәткәр вазифасының һәм һөнәренең ятим балалар оешмаларында эшчеләр гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация

дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.7. Ятим балалар оешмаларында берьюлы ике урында, шулай ук эш вакыты тулы булмаган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә йә башкарылган эшләр күләменә карап гамәлгә ашырыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук төп урыннан тыш башка урында эшләү тәртибендә биләнә торган вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым билгеләнә.»;

VI бүлектә:

6.3 пунктта:

икенче абзацында «444 сум» сүзләрен «1 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацында «833 сум» сүзләрен «1 500 сум» сүзләренә алмаштырырга;

6.4 пунктның бишенче абзацында «3 процент» сүзләрен «5 процент» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлекнең 15 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 нче таблица

Ятим балалар оешмалары җитәкчеләренең база окладлары һәм башкарыла торган эшләренең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр күләмнәре

| База окладьі, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләү, сум |
|---|---|
| 57 000 | 9 000». |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин